ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.07.2026 г. Заинск № 353

**Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 гыйнварындагы 03 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җылылык, электр-ягулык һәм су белән тәэмин итүче оешмаларының, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт - төзелеш һәм транспорт оешмаларының үзара хезмәттәшлеген исәпкә алып җылылык белән тәэмин итү системаларында авария хәлләрен бетерү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Биналар һәм корылмалар иминлеге турында техник регламент «Федераль законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 25 декабрендәге 653-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 гыйнварындагы 03 номерлы «Җылылык, электр-ягулык һәм су белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт - төзелеш һәм транспорт оешмаларының үзара хезмәттәшлеген исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында авария хәлләрен бетерү тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3. пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

“инженер-техник тәэмин итү челтәре - электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәре, элемтә челтәре һәм бинаны һәм (яисә) корылманы инженер-техник тәэмин итү өчен билгеләнгән башка корылмалар, шулай ук мондый челтәрләр җыелмасы;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар ул басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **Р.М.Сәхәбетдинова**

Гөбәйдулина И.В.
8(85558) 9-90-55